# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

1 статья. "Мәгариф турында" 1993 елның 19 октябрендәге Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, N 10), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

"Мәгариф турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Мәгариф шәхес, җәмгыять һәм дәүләт ихтыяҗлары өчен максатчан белем алудан һәм тәрбиядән гыйбарәт, ул гражданның белем алуда мәгълүм бер дәрәҗәгә ирешүе белән билгеләнә һәм ул белем турындагы тиешле документта раслана.

Шәхеснең белем, тәрбия һәм мәдәниятлелек дәрәҗәсе дәүләтнең, гаиләнең, җәмәгать берләшмәләренең һәм шәхеснең үзенең уртак тырышлыгы белән тәэмин ителә.

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәте

Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсен өстенлекле дип

игълан итә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана торган Мәгарифне үстерү буенча комплекслы дәүләт программасы Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендәге дәүләт сәясәтенең оештыру нигезе булып тора. Комплекслы дәүләт программасы конкурс нигезендә эшләнә һәм төзәтелә. Конкурсны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты игълан итә.

2 статья. Мәгариф турында Татарстан Республикасы законнары

1. Татарстан Республикасының мәгариф турындагы законнарына Татарстан Республикасының Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары керә.

2. Мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Татарстан Республикасы гражданнарының белемгә конституциячел хокукларын тәэмин итү һәм яклау;
- Татарстан Республикасында мәгариф системасының ирекле эшчәнлеге һәм үсеше өчен хокукый гарантияләр булдыру;
- мәгариф өлкәсендә физик һәм юридик затларның вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын билгеләү;
- мәгариф өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең төрле дәрәҗәдәге органнары арасындагы вәкаләтләрне бүлешү;
- мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәте принципларын билгеләү.

3. Татарстан Республикасының мәгариф турындагы законнарын бозган юридик һәм физик затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә җавапка тартылалар.

3 статья. Гражданнарның белемгә хокукы

1. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы гражданнары, милләтенә, теленә, җенесенә, яшенә, сәламәтлегенә, социаль һәм мөлкәти халәтенә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, нинди фиркадә булуына һәм башка шартларга карамастан, дәүләт мәгариф стандарты чикләрендә белем алуга хокуклы.

Җенесенә, яшенә, сәламәтлегенә, хөкем ителгәнлегенә карап, гражданнарның һөнәри белем алуга хокукын чикләүләр бары

тик закон нигезендә һәм суд карары белән билгеләнергә мөмкин.

2. Гражданнарның белем алу хокукы дәүләт тарафыннан Татарстан Республикасында мәгариф системасы һәм белем алу өчен социаль-икътисадый шартлар булдыру юлы белән тәэмин ителә.

3. Социаль яклауга һәм ярдәмгә мохтаҗ гражданнарның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру максатларында аларның белем алу чорындагы чыгымнарын тулысынча яисә өлешчә дәүләт күтәрә. Әлеге ярдәм күрсәтелүче гражданнарның категорияләрен, ярдәмнең төрен, күләмен һәм чыганакларын законнар билгели.

4. Татарстан Республикасы гражданнары үзлекләреннән белем алу рәвешендә мәгариф учреждениесе курсын үзләштерү, экстерн юлы белән имтиханнар тапшыру һәм тиешле белем һәм (яисә) белгечлек турында документ алу хокукына ия.

5. Татарстан Республикасы гражданнары бушлай урта гомуми, башлангыч һәм урта һөнәр белемен алуга һәм белем бирүнең дәүләт стандартлары чикләрендә мәгарифнең барлык төр учреждениеләрендә, әгәр граждан мондый дәрәҗәдәге белемне беренче тапкыр алса, конкурс нигезендә түләүсез югары һөнәр белеме алуга хаклы.

Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләрендә белем бирүнең дәүләт стандарты чикләрендә белем бирү өчен тотылган чыгымнар тиешле төрдәге һәм рәвештәге дәүләт мәгариф учреждениесендә белем алу өчен билгеләнгән дәүләт нормативлары күләмендә дәүләт тарафыннан компенсацияләнә.

6. Урта һөнәр һәм югары һөнәр белеме бирү дәүләт мәгариф учреждениеләренә керү имтиханнарын уңышлы биргәндә, ятим балалар һәм ата-аналары каравыннан мәхрүм балалар, табиб-хезмәт комиссиясе нигезләмәсе буенча әлеге мәгариф учреждениеләрендә уку рөхсәт ителгәндә, I һәм II төркем гарипләр конкурстан тыш кабул ителәләр.

7. Белем алырга сәләтләрен күрсәткән гражданнарга дәүләт, чит илләрдә укуны да кертеп, мәгарифнең дәүләт стандартларыннан югарырак белем алуда ярдәм итә.

Гражданнар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә махсус дәүләт стипендияләре алырга хокуклы.

8. Дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләрен тәмамлаучылар мәгарифнең шуннан соңгы дәрәҗәдәге учреждениелә-

ренә кабул итүдә бертигез хокукларга ия.

9. Башка дәүләтләрнең гражданнарына Татарстан Республикасындагы мәгариф учреждениеләрендә белем алу хокукы Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре нигезендә бирелә.

4 статья. Мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принциплары

Мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Мәгарифнең кешелекле, халыкчан һәм милли рухта булуы, гомумкешелек хәзинәләренең, кеше гомеренең һәм сәламәтлегенең, шәхеснең ирекле үсешенең өстенлеге.

2. Мәгарифнең дәүләт стандарты чикләрендә, әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм кеше өчен мөмкин һәм түләүсез булуы.

3. Укытуның һәм тәрбиянең бердәмлеге, мәктәпнең, мәктәпкәчә учреждениенең, гаиләнең, җәмәгать берләшмәләренең һәм хезмәт коллективларының балаларны һәм яшьләрне тәрбияләгәндә үзара хезмәттәшлеге.

4. Укытуның тормыш һәм милли мәдәни гореф-гадәтләр белән бәйлелеге.

5. Дәүләт мәгариф системасының гыйльми һәм дөньяви рухта булуы.

6. Мәгариф учреждениеләренең һәр төрендә уку-укыту системасының бердәмлеге, өзлексез, дәвамлы һәм буыннан-буынга күчүчән булуы.

7. Белем алу телен сайлау иреге һәм мәктәптә ана телендә укуга хокук.

8. Мәгариф белән идарә итүнең демократик дәүләти иҗтимагый рухта булуы. Мәгариф учреждениеләренең автономлыгы.

9. Дәүләт мәгариф учреждениеләренең фиркаләр, дини һәм башка җәмәгать берләшмәләре идеология билгеләмәләреннән һәм карарларыннан бәйсез булуы.

5 статья. Милли мәгариф учреждениеләр

Милли мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеге, гомумкешелек хәзинәләренең өстенлегеннән чыгып, шәхеснең милли үзаңын торгызуга юнәлдерелә. Милли мәгариф учреждениеләрендә укыту һәм

тәрбия Татарстан Республикасында мәгариф үсеше концепциясе нигезендә алып барыла.

Милли мәгариф учреждениеләрендә белем бирү Татарстан Республикасының дәүләт мәгариф стандартларына туры килә.

6 статья. Белем алу теле (телләре)

1. Татарстан Республикасы гражданнары татар яки рус телләрендә, шулай ук мәктәптә ана телендә белем алырга хокуклы.

2. Татар һәм рус телләре, Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә, гомуми белем мәктәпләрендә, башлангыч, урта һөнәр белеме учреждениеләрендә бертигез күләмнәрдә өйрәнелә.

3. Тиешле һөнәр белгечләрен сыйфатлы әзерләүне һәм яңадан әзерләүне тәэмин итү максатларында югары һәм урта һөнәр белеме учреждениеләрендә укыту Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, шулай ук чит телләрдә алып барыла.

4. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты халыкара шартнамәләр һәм Россия Федерациясе субъектлары белән төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы территориясеннән читтә яшәүче татарларга туган телләрендә кирәкле белем алырга ярдәм итә.

7 статья. Мәгарифнең дәүләт стандартлары

1. Татарстан Республикасында гомуми белем учреждениеләренең (мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми (тулы булмаган урта), гомуми урта (тулы) һәм һөнәр белеме) һәр баскычында укытуга һәм тәрбиягә карата база таләпләрен, укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең уку-хезмәт йөкләмәләренең максималь күләмен, уку-укыту программалары эчтәлегенең тиешле минимумын билгеләү буенча мәгарифнең дәүләт стандартлары урнаштырыла.

2. Уку-укыту программалары эчтәлегенең тиешле минимумы белән бергә укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең ихтыяҗларына һәм мәнфәгатьләренә туры килерлек башка төр программалар, дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре кертелә.

3. Үсешләрендә кимчелек булган укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру йөзеннән дәүләт

мәгарифенең махсус (коррекцияле) стандартлары билгеләнә.

4. Мәгарифнең дәүләт стандартлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

5. Мәгарифнең дәүләт стандартларының милли-төбәк компонентлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кимендә ун елга бер тапкыр конкурс нигезендә эшләнә.

## П бүлек. Татарстан Республикасында мәгариф системасы

### 8 статья. Мәгариф системасы төшенчәсе

1. Татарстан Республикасында мәгариф системасы бер-берсенең дәвамы булган төрле дәрәҗәдәге уку-укыту программаларының җыелмасыннан, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган гомуми белем, һөнәр белеме һәм башка мәгариф учреждениеләре челтәреннән, дәүләт мәгариф идарәсе органнарыннан, предприятиеләреннән, учреждениеләр һәм оешмаларыннан гыйбарәт.

### 9 статья. Белем алу рәвешләре

1. Шәхеснең мөмкинлекләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып, уку-укыту программалары түбәндәге рәвешләрдә үзләштерелергә мөмкин: белем бирү учреждениеләрендә - җитештерүдән аерылып, аерылып һәм аерылмыйча (кичке), аерылмыйча; гаиләдә белем алу, үзлегеннән белем алу яисә экстернат рәвешендә.

Белем алуның төрле рәвешләрен бергә-бергә алып барырга да мөмкин.

2. Уку-укыту программасы чикләрендә, белем алу рәвешенә карамастан, дәүләт мәгарифенең бердәм стандарты гамәлдә була.

3. Җитештерүдән аерылып һәм аерылмыйча (кичке), аерылмыйча һәм экстернат рәвешендә белем алырга мөмкин булмаган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

10 статья. Уку-укыту программалары

1. Татарстан Республикасында түбәндәгеләргә бүленүче уку-укыту программалары гамәлгә ашырыла:

а) гомуми белем (төп, өстәмә);

б) һөнәр белеме (төп, өстәмә).

2. Гомуми белем программалары шәхеснең гомуми зыялылыгына ирешү, җәмгыятьтә кешенең тормышка җайлашуы (адаптация) мәсьәләләрен, һөнәр белеме программаларын аңлы рәвештә сайлау һәм үзләштерү өчен шартлар тудыру мәсьәләләрен хәл итә.

3. Гомуми белем программалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) мәктәпкәчә белем бирү;

б) башлангыч белем бирү;

в) төп гомуми (тулы булмаган урта) белем бирү;

г) гомуми урта (тулы) белем бирү.

4. Һөнәр белеме программалары һөнәр һәм гомуми белем дәрәҗәсенең эзлекле үсешен, тиешле белгечлек өчен белгечләр әзерләүне тәэмин итәләр.

Һөнәр белеме программалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) башлангыч һөнәр белеме;

б) урта һөнәр белеме;

в) югары һөнәр белеме;

г) югары уку йортларыннан соңгы һөнәр белеме (ординатура, адъюнктура, аспирантура һ.б.ш.).

5. Гомуми белемнең һәр төп программасы яисә һөнәр белеменең төп программасы (билгеле бер һөнәр, белгечлек буенча) эчтәлегенең мәҗбүри минимумы мәгарифнең дәүләт стандарты тарафыннан билгеләнә.

6. Мәгарифнең дәүләт стандартлары чикләреннән тыш, барлык баскычларда да гомуми белемнең һәм (яисә) һөнәр белеменең өстәмә программалары үзләштерелергә мөмкин.

7. Дәүләт мәгариф учреждениеләрендә һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениеләрендә төп белем бирү программаларын үзләштерүнең норматив вакытлары әлеге Закон һәм (яисә) тиешле типтагы һәм төрдәге мәгариф учреждениеләре турында бер үрнәктәге нигезләмәләр белән билгеләнә.

11 статья. Гомуми белем программаларын гамәлгә ашыру

1. Гомуми белем программалары мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп, (тулы булмаган урта), гомуми урта (тулы), башлангыч һәм урта һөнәр белеме учреждениеләрендә, шул исәптән үсешләрендә кимчелек булган укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, ятим балалар һәм ата-аналары тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен белем бирү учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең уку-укыту программалары укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең психофизик үсешендәге үзенчәлекләрен һәм мәмкинлекләрен исәпкә алып, төп гомум белем программалары нигезендә эшләнә.

3. Мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп (тулы булмаган урта) һәм гомуми урта (тулы) белемнең уку-укыту программалары бер-берсенең дәвамы булып торалар, ягъни һәр яңа программа алдагы программа нигезендә төзелә.

4. Гомуми башлангыч һәм төп гомуми (тулы булмаган урта) белем баскычында укып та, уку елы программасын үзләштермәгән һәм ике яисә аннан да күбрәк фәннән академик бурычы булган укучылар ата-аналары (аларның законлы вәкилләре) ризалыгы белән кабат укытырга калдырылалар яисә бер укытучыга туры килүче укучылар саны азрәк булган компенсацияле укыту сыйныфына күчереләләр яки гаиләдә белем алу рәвешендә укуларын дәвам итәләр. Алда күрсәтелгән белем баскычында укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең берәр предмет буенча академик бурычы булса, алар алдагы сыйныфка шартлы рәвештә күчереләләр. Академик бурычларын киләсе уку елы дәвамында үтәү җаваплылыгы аларның ата-аналарына (аларның законлы вәкилләренә) йөкләнә.

Укучыны, тәрбияләнүчене алдагы сыйныфка күчерү мәсьәләсе мәгариф учреждениесенең идарә органы карары нигезендә башкарыла.

5. Укучыларны, тәрбияләнүчеләрне гомуми белем программалары чикләрендә хезмәткә әзерләү гомуми белем мәктәпләрендә, гимназияләрендә, лицейларда, мәктәпара укыту-житештерү комбинатларында, башлангыч һәм урта һөнәр белеме учреждениеләрендә, өйрәнү цехларында һәм предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, урта махсус, югары уку йортлары, фәнни-тикшеренү инсти-

тутлары участокларында гамәлгә ашырыла.

6. Гомуми урта (тулы) белем бирүнең дәүләт мәгариф стандарты, алынучы һөнәр белеме профилен исәпкә алып, башлангыч һөнәр яисә урта һөнәр белеме программалары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Үткән баскычның уку-укыту программасын үзләштермәгән укучылар, тәрбияләнүчеләр гомуми белемнең алдагы баскычына күчерелмиләр.

<u>12 статья.</u> Мәгариф учреждениесен гамәлгә куючы (гамәлгә куючылар)

1. Мәгариф учреждениесенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) түбәндәгеләр булырга мөмкин:

а) дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары;

б) үз илебезнең һәм чит илләрнең төрле милек рәвешләрендәге оешмалары, аларның берләшмәләре;

в) үз илебезнең һәм чит илләрнең җәмәгать һәм шәхси фондлары;

г) Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән иҗтимагый һәм дини оешмалар;

д) Татарстан Республикасының һәм башка дәүләтләрнең гражданнары.

2. Девиант (җәмгыять өчен куркыныч) тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен ябык типтагы укыту-тәрбияләү махсус учреждениеләрен бары тик Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең республика органнары гына гамәлгә куя ала.

3. Гамәлгә куючы белән мәгариф учреждениесе арасындагы мөнәсәбәтләр законнар нигезедә алар арасында төзелгән шартнамә белән билгеләнә.

<u>13 статья.</u> Мәгариф учреждениеләре

1. Бер яисә берничә уку-укыту программасын гамәлгә ашыру аша белем бирүче һәм укучыларны, тәрбияләнүчеләрне караучы һәм тәрбияләүче учреждение мәгариф учреждениесе була.

2. Мәгариф учреждениеләренә түбәндәге типтагы учреждение-

ләр кирә:

- мәктәпкәчә белем;
- гомуми белем (гомуми башлангыч, гомуми тулы (тулы булмаган урта), гомуми урта (тулы) белем);
- башлангыч һөнәр, урта һөнәр, югары һәнәр һәм югары уку йортыннан соңгы һөнәр белеме учреждениеләре;
- өлкәннәр өчен өстәмә белем бирү учреждениеләре;
- үсешләрендә кимчелек булган балаларны укыту өчен махсус (коррекцияле) белем учреждениеләре;
- балалар өчен өстәмә белем учреждениеләре;
- ятим балалар һәм ата-анасыз (аларның законлы вәкилләресез) калган балалар өчен учреждениеләр;
- белем бирүче башка учреждениеләр.

3. Мәгариф учреждениеләре дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләргә бүленергә мөмкин. Мәгариф әлкәсендә Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы территориясендәге барлык мәгариф учреждениеләренә дә, аларның кемгә буйсынуларына карамастан кагыла.

4. Мәгариф өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы территориясендәге, аларның оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез төстә, барлык мәгариф учреждениеләренә кагыла.

5. Мәгариф учреждениесе хокукый зат була.

6. Дәүләт мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеге мәгариф учреждениеләренең тиешле типлары һәм төрләре турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган уртак нигезләмәләр һәм әлеге мәгариф учреждениеләренең шулар нигезендә төзелгән уставлары белән җайга салына.

Уртак нигезләмәләр дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре өчен үрнәк вазыйфасын үти.

7. Мәгариф учреждениеләре ассоциацияләр, берлекләр һәм башка мәгариф берләшмәләре төзи алалар, шул исәптән предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар катнашында да. Әлеге мәгариф учреждениеләрен теркәү тәртибе һәм аларның эшчәнлеге законнар белән билгеләнә.

8. Законнарда каралган өстәмә белем бирү учреждениеләренең хокуклары һәм бурычлары, бары тик өстәмә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өлешендә генә, уставының төп максаты

белем бирү эшчәнлеге булган иҗтимагый берләшмәләргә дә кагыла.

9. Мәгариф учреждениесенең статусы (гамәлгә ашырылучы уку-укыту программаларының дәрәҗәсе һәм юнәлеше нигезендә билгеләнүче мәгариф учреждениесенең тибы һәм төре) аны лицензияләгәндә билгеләнә.

<u>14 статья.</u> Мәгариф учреждениесенең уставы

I. Мәгариф учреждениесенең уставы гражданлык законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш, анда түбәндәге белешмәләрне күрсәтү мәҗбүри:

1) Мәгариф учреждениесенең исеме, урнашкан җире һәм статусы.

2) Мәгариф учреждениесен гамәлгә куючы.

3) Мәгариф учреждениесенең оештыру-хокукый рәвеше.

4) Белем бирүнең максатлары, гамәлгә ашырылучы уку-укыту программаларының типлары һәм төрләре.

5) Белем бирүне оештыруның төп үзенчәлекләре, шул исәптән:

а) укыту һәм тәрбия алып барыла торган тел (телләр);

б) укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне кабул итү тәртибе;

в) укытуның һәр этабында укытуның дәвамлылыгы;

г) укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне мәгариф учреждениеләреннән чыгару тәртибе һәм сәбәпләре;

д) арадаш аттестациядә билгеләр системасы, аның рәвешләре һәм аны уздыру тәртибе;

е) укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең дәресләр режимы;

ж) уку-укытуда түләүле хезмәт күрсәтүләр булу һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе;

з) мәгариф учреждениесе белән укучылар, тәрбияләнүчеләр һәм (яисә) аларның ата-аналары (аларның законлы вәкилләре) арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салу һәм рәсмиләштерү тәртибе.

6) Мәгариф учреждениесенең финанс һәм хуҗалык эшчәнлеге төзелеше, шул исәптән:

а) гамәлгә куючы мәгариф учреждениесенә беркеткән милек объектларыннан файдалану;

б) мәгариф учреждениесенең эшчәнлеген финанслау һәм матди-техник яктан тәэмин итү;

в) мәгариф учреждениесе милкенең чыганаклары һәм оешу тәртибе;

г) эшкуарлык гамәле булу.

7) Мәгариф учреждениесе белән идарә итү тәртибе, шул исәптән:

а) гамәлгә куючының вәкаләте;

б) мәгариф учреждениесенең идарә органнары төзелеше, аларны оештыру тәртибе, аларның вәкаләтләре һәм эшчәнлекләрен оештыру тәртибе;

в) мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләрен туплау тәртибе һәм аларга хезмәт өчен түләү шартлары;

г) мәгариф учреждениесенең уставын үзгәртү тәртибе;

д) үзгәртеп кору һәм ябу тәртибе.

8) Уку-укыту барышында катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары.

9) Мәгариф учреждениесенең эшчәнлеген җайга салучы эчке актлар төрләренең (боерыклар, күрсәтмәләр һ.б.актлар) исемлеге.

2. Мәгариф учреждениесе уставының законнар белән җайга салынмаган өлеше аның үзе тарафыннан мөстәкыйль әзерләнә һәм ул гамәлгә куючы тарафыннан раслана.

3. Мәгариф учреждениесе эшчәнлегенең әлеге статьяда күрсәтелгән якларын башка эчке актлар нигезендә билгеләргә кирәк булганда, соңгылары уставка өстәмә рәвешендә теркәлергә тиеш.

4. Мәгариф учреждениесенең эчке актлары уставка каршы килә алмыйлар.

<u>15 статья.</u> Мәгарифнең асылына карата гомуми таләпләр

1. Мәгарифнең асылы җәмгыятьнең икътисадый һәм иҗтимагый алгарышының бер чагылышы булып тора һәм түбәндәгеләрне күз алдында тотарга тиеш:

- шәхеснең үзбилгеләнүен тәэмин итүне, шәхес үз сәләтен гамәлгә ашырсын өчен шартлар тудыруны;
- гражданлык җәмгыяте үсешен;
- хокукый дәүләтне ныгытуны һәм камилләштерүне;
- Татарстан Республикасы халыкларының рухи байлыгын һәм интеллектуаль куәтен арттыруны.

2. Мәгарифнең асылы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- укучының, тәрбияләнүченең дөньяга карашын заман белемнәре дәрәҗәсенә һәм уку-укыту программасы дәрәҗәсенә (белем алу дәрәҗәсенә) туры китерүне;

- җәмгыятьнең гомуми һәм һөнәр мәдәниятенең дәрәҗәсен бөтендөнья дәрәҗәсенә туры китерүне;

- бөтендөнья һәм милли мәдәниятләр системасында шәхеснең үз урынын табу мөмкинлеген;

- хәзерге заман җәмгыятенә яраклашкан һәм әлеге җәмгыятьне камилләштерүгә омтылучан кешене һәм гражданны тәрбияләүне.

3. Теләсә-кайсы дәрәҗәдәге һөнәр белеме укучыларның һөнәр үзләштерүен һәм тиешле белгечлеккә ирешүен тәэмин итәргә тиеш.

4. Мәгарифнең асылы кешеләр, халыклар, төрле расалар, милләтләр, этник, дини һәм социаль төркемнәр арасында үзара аңлашуга һәм хезмәттәшлеккә ярдәм итәргә; дөньяга карашларның төрлелеген исәпкә алырга, укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең карашларны һәм инануларны ирекле сайлау хокукларын гамәлгә ашыруда булышырга тиеш.

5. Аерым мәгариф учреждениесендә мәгарифнең асылы әлеге мәгариф учреждениесе тарафыннан мөстәкыйль эшләнүче, кабул ителүче һәм гамәлгә ашырылучы уку-укыту программасы (уку-укыту программалары) нигезендә билгеләнә.

Мәгариф белән идарә итүче дәүләт органнары уку-укытуның үрнәк программаларын (экспертизаны) эшләүне һәм аларны дәүләт стандартларына туры китерүне тәэмин итәләр.

6. Мәгариф учреждениесе үз уставындагы максатлары һәм бурычлары нигезендә, уку-укыту программалары статусын билгеләүче чикләрдән тыш, өстәмә уку-укыту программаларын да гамәлгә ашыра ала.

## 16 статья. Белем бирүнең барышын оештыруга куелган гомуми таләпләр

1. Мәгариф учреждениесендә белем бирүнең барышын оештыру мәгариф учреждениесе тарафыннан мөстәкыйль, уку йөкләмәләренең иң чик мөмкин күләме һәм төп уку-укыту программаларының мәҗбүри минимумы чикләрендә эшләнгән һәм расланган укыту планы (уку курслары һәм фәннәр буенча, уку еллары буена уку-укыту прог-

раммаларының эчтәлегенә карап), календарь елының уку графигы һәм дәресләр расписаниесе нигезендә җайга салына.

2. Әгәр законнарда башка очраклар каралмаса, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары мәгариф учреждениесенең укыту планын һәм укыту графигын расланганнан соң үзгәртә алмыйлар.

3. Мәгариф учреждениесе укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең бер баскычтан икенче баскычка күчкәндә аттестацияләү рәвешен, тәртибен һәм даимилеген мөстәкыйль сайлый ала.

4. Гомуми төп (тулы булмаган урта), гомуми урта (тулы) һәм һөнәр белеменең барлык төрләре буенча уку-укыту программаларын үзләштерү укуны тәмамлаучыларның махсус йомгаклау имтиханнары белән тәмамлана.

5. һәр дәрәҗәдәге белем алуны тәмамлау буенча укучыларның йомгаклау имтиханнарын һәм әзерлек сыйфатын тикшерүне фәнни-ысулый тәэмин итү мәгарифнең дәүләт стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Мәгариф учреждениесендәге тәртип укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең һәм укытучыларның кешелек хисләрен ихтирам итеп урнаштырыла. Укучыларга, тәрбияләнүчеләргә карата физик һәм психик басым ясау алымнары куллану тыела.

7. Балигъ булмаган укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарына (аларның законлы вәкилләренә) укытуның барышы һәм эчтәлеге, шулай ук аларның өлгерешенә куелган билгеләр белән танышу мөмкинлеге тәэминителергә тиеш.

<u>17 статья.</u> Мәктәпкәчә мәгариф

1. Ата-аналар яисә аларны алмаштыручы затлар беренче педагоглар булалар. Алар баланың шәхес буларак физик, әхлакый һәм акыл үсешенә нигез салырга, аңарда туган телгә мәхәббәт тәрбияләргә һәм туган телне өйрәтергә тиешләр.

2. Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү, аларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту, балаларның үсешендәге кимчелекләрне бетерү өчен шартлар тудыру буенча гаиләгә ярдәм күрсәтәләр.

3.Дәүләт иртә яшьтәге балаларны тәрбияләүдә финанс һәм матди яктан тәэмин итүне гарантияли, мәктәпкәчә мәгариф учреж-

дениесенең белем бирү хезмәтләрен халыкның барлык катлаулары өчен кабул ителерлек булуын тәэмин итә.

4. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм ата-аналар (аларның законлы вәкилләре) арасындагы мөнәсәбәтләр үзара килешү белән җайга салына, ул якларның закон билгеләгән хокукларын чикли алмый.

5. Дәүләт мәгариф идарәсенең җирле органнары мәктәпкәчә яшьтәге балаларны өйдә тәрбияләүче гаиләләргә ысулый, диагностик һәм консультатив ярдәм оештыра һәм аны килештерә.

<u>18 статья.</u> Гомуми белем

1. Гомуми белем мәгариф системасының төп буыны булып тора һәм һәр гражданга үзенең сәләтенә, мәнфәгатьләренә һәм омтылышларына туры килерлек белем алу өчен һәм укуын дәвам итү өчен тигез мөмкинлекләр булдыра.

2. Гомуми белем өч баскычны үз эченә ала:

башлангыч гомуми, төп гомуми (тулы булмаган урта), урта (тулы) гомуми белем.

Белем бирүнең һәр баскычында укучының яше һәм белеменең дәвамлылыгы мәгариф учреждениесе уставы нигезендә билгеләнә.

3. Төп гомуми (тулы булмаган урта) белем һәм дәүләт (йомгаклау) аттестациясе мәҗбүри була.

4. Аерым бер укучыга кагылышлы төп гомуми белемнең мәҗбүрилеге таләбе, әгәр тиешле белем элегрәк алынмаса, ул унбиш яшенә җиткәнчегә кадәр үз көчендә була.

5. Дәүләт мәгариф учреждениеләренең гомуми башлангыч, гомуми төп (тулы булмаган урта), гомуми урта (тулы) белем баскычларына кабул итү тәртибен, тиешле дәрәҗәдәге белем алуга хакы булган һәм әлеге территориядә яшәгән барлык гражданнарны кабул итүне тәэмин итә торган гамәлгә куючы билгели.

Уку-укыту программасы аеруча катлаулы булган мәгариф учреждениеләренең беренче баскычына кабул итү конкурс нигезендә һәм медицина - педагогия комиссиясенең нәтиҗәләрен исәпкә алып үткәрелергә мөмкин.

6. Гомуми белем учреждениесендә производстводан аерылып гомуми төп (тулы булмаган урта) белем алу укучының унсигез яше белән чикләнә. 45 статьяның 7,8,11 пунктларында күрсәтелгән

категория укучылары өчен гомуми төп (тулы булмаган урта) белемне үзләштерү яше арттырылырга мөмкин.

7. Ата-аналар (аларның законлы вәкилләре) белән дәүләт мәгариф идарәсе җирле органының үзара килешүе буенча унбиш яшькә җиткән укучы гомуми төп (тулы булмаган урта) белемне үзләштереп бетергәнче үк мәгариф учреждениесеннән китә ала.

8. Хокукка каршы гамәлләр кылган өчен, мәгариф учреждениесенең уставын тупас рәвештә һәм берничә мәртәбә бозган өчен ундүрт яшькә җиткән укучыларны, тәрбияләнүчеләрне гомуми белем бирү учреждениесе идарәсе органының карары буенча әлеге мәгариф учреждениесеннән чыгару рөхсәт ителә.

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән башка үсүче балаларны әлеге мәгариф учреждениесеннән чыгару опека һәм кайгырту-тәрбия органнары белән килешеп башкарыла.

Мәгариф учреждениесе укучыны, тәрбияләнүчене укуыннан чыгару турындагы хәбәрне җирле администрациягә, җирле үзидарә органнарына өч көн эчендә җиткерергә тиеш.

Җирле администрация, җирле үзидарә органнары, укудан чыгарылган балаларның ата-аналары (аларның законлы вәкилләре) белән берлектә, бер ай эчендә аны эшкә урнаштыруны яисә башка мәгариф учреждениесендә укуын дәвам итүне тәэмин итүче чаралар күрәләр.

__19 статья.__ Гомуми белем мәктәпләренең аерым төрләре, интернат-мәктәпләр, мәктәп яны интернатлары, балалар йортлары

1. Укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең һәрьяклы үсешенә тагын да уңайлырак шартлар тудыру, шулай ук балаларны укытуда һәм тәрбияләүдә гаиләгә ярдәм күрсәтү максатларында, кирәкле укыту-матди нигез җитәрлек булганда, законнарда билгеләнгән тәртиптә озайтылган көнле гомуми белем мәктәпләре яисә озайтылган көн төркемнәре, кайбер фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәпләре һәм сыйныфлары, шул исәптән гимназияләр, лицейлар, колледжлар, сәнгать мәктәпләре, спорт мәктәпләре, гомуми белем мәктәпләре - комплекслар, интернат мәктәпләр, мәктәп яны интернатлары һәм башкалар төзелә.

2. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балалар,

милләтенә карап, балалар йортларында, нәниләр йортларында, гомуми белем интернат- мәктәпләрендә, гаилә балалар йортларында тәрбияләнәләр һәм тулысынча дәүләт тәэминатында булалар.

20 статья. Һөнәр белеме программаларын гамәлгә ашыру. Һөнәри әзерлек

1. Һөнәр белеме программалары, шул санда үсешендә тоткарланган укучылар, тәрбияләнүчеләр һәм гарипләр өчен дә, һөнәр белеме мәгариф учреждениеләрендә, шул санда үсешендә тоткарланган укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт аккредитациясе булган һөнәр белеме мәгариф учреждениеләре әлеге белем бирү программаларын квалификацияле хезмәт эшчәннәре (эшчеләр һәм хезмәткәрләр) һәм тиешле дәрәҗәдәге белгечләр әзерләү максатларында гамәлгә ашыралар.

2. Теләсә нинди башка һөнәр белеме булу гражданнарны һөнәр белеме мәгариф учреждениесенә кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

3. Һөнәр әзерлеге башлангыч һөнәр белем бирү мәгариф учреждениеләрендә һәм башка мәгариф учреждениеләрендә: мәктәпара укыту комбинатларында, укыту-җитештерү остаханәләрендә, өйрәнү участокларында (цехларында), шулай ук тиешле лицензиясе булган оешмаларның белем бирү подразделениеләрендә, аттестация үткән һәм тиешле лицензиясе булган белгечләрдә шәхси әзерлек тәртибендә бирелә ала.

4. Гомумбелем учреждениеләре шартнамәләр буенча һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар белән бергә әлеге эшчәнлек төренә тиешле лицензиясе (рөхсәте) булганда өстәмә (шул санда түләүле) мәгариф хезмәте күрсәтү сыйфатында укучыларны профессиональ әзерләүне уздыра алалар. Башлангыч һөнәр әзерлеге тик укучыларның һәм аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) ризалыгы белән генә уздырыла.

21 статья. Башлангыч һөнәр белеме

1. Башлангыч һөнәр белеме эшче кадрлар әзерләүне максат итеп куя. Башлангыч һөнәр белеме алу өчен минималь белем дәрә-

җәсе булып төп гомуми (тулы булмаган урта) белем бирү тора.

Аерым һөнәрләр буенча башлангыч һөнәр белеме урта (тулы) гомуми белемгә таяна ала.

Кирәк булган очракларда дәүләт төп гомуми (тулы булмаган урта) белеме булмаган затларга һөнәр алу өчен шартлар тудыра.

2. Башлангыч һөнәр белеме башлангыч һөнәр белеме мәгариф учреждениеләрендә (һөнәр-техник һәм әлеге дәрәҗәдәге башка училищеларда) алынырга мөмкин.

3. Дәүләт мәгариф учреждениеләрендә башлангыч һөнәр белеме һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениеләрендә беренче һөнәрен алган гражданнар, шулай ук эшкә урнаштыру хезмәте юлламасы буенча укучылар түләүсез укыйлар.

<u>22 статья.</u> Урта һөнәр белеме

1. Урта һөнәр белеменең максаты төп (тулы булмаган урта), гомуми (тулы) урта белем яисә башлангыч һөнәр белеме нигезендә белгечләр әзерләүдән, аларны яңа белгечлеккә өйрәтүдән, белгечлекләрен күтәрүдән гыйбарәт.

2. Урта һөнәр белеменең мәгариф учреждениеләрендә (махсус урта уку йортларында) яисә югары һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләренең беренче баскычында урта һөнәр белемен үзләштерергә мөмкин.

3. Гомуми төп (тулы булмаган урта) белеме булган гражданнар урта һөнәр белемен үзләштерү белән бергә гомуми урта (тулы) белем дә алалар.

Урта һөнәр белеменең мәгариф учреждениеләре, тиешле лицензияләре булганда, башлангыч һөнәр белеменең укыту программаларын да гамәлгә ашыра алалар.

4. Урта һөнәр белеменең дәүләт мәгариф учреждениеләрендә һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениеләрендә беренче һөнәрен яисә белгечлеген үзләштерүче, шулай ук эшкә урнаштыру хезмәте юлламасы нигезендә белем алучы гражданнар өчен уку түләүсез була.

5. Тиешле юнәлештәге гомуми урта (тулы) яисә гомуми башлангыч һөнәр белеме булган гражданнар урта һөнәр белемен тизләтелгән программа буенча алалар.

324



<u>23 статья.</u> Югары һөнәр белеме

1. Татарстан Республикасында югары һөнәр белеме, тиешле юнәлештә белгечләр әзерләү гомуми урта (тулы) һәм урта һөнәр белеме нигезендә шәхеснең белемен арттыруга һәм тирәнәйтүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү, Татарстан Республикасының икътисадый һәм хокукый нигезен ныгыту, милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне үстерү максатларын күздә тота.

2. Югары белем югары һөнәр белеме мәгариф учреждениеләрендә (университетларда һәм башка югары уку йортларында) үзләштерелә.

3. Тиешле юнәлештәге башлангыч һәм урта һөнәр белеме булган затлар югары һөнәр белемен кыскартылган һәм тизләтелгән программа нигезендә үзләштерә алалар.

<u>24 статья.</u> Югары уку йортыннан соңгы һөнәр белеме

1. Югары уку йортыннан соңгы һөнәр белеме гражданнарга югары һөнәр белеме базасында белем дәрәҗәләрен күтәрү, фәнни һәм педагогик белгечлекләрен камилләштерү мөмкинлеге тудыра.

2. Югары уку йортыннан соңгы һөнәр белеме югары һөнәр белеме мәгариф учреждениеләрендә һәм фәнни учреждениеләрендә булдырылучы аспирантурада, ординатурада һәм адъюнктурада алынырга мөмкин.

<u>25 статья.</u> Өстәмә һөнәр белеме

1. Өстәмә һөнәр белеме (белгечлекне күтәрү һәм кадрларны яңа һөнәргә өйрәтү) башлангыч урта һәм югары һөнәр белеме учреждениеләрендә, белгечлекне күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәтү институтларында, белгечлекне камилләштерү институтларында, фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә һәм башка учреждениеләрдә кызыксынучы яклар арасында төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Белгечлекне күтәрү һәм кадрларны яңа һөнәргә өйрәтүне тикшереп тору предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның, шулай ук министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарның җитәкчеләренә йөкләнә.

3. Белгечлекне күтәрү һәм кадрларны яңа һөнәргә өйрәтү буенча уку йортларының, шулай ук аларның филиалларының эшчәнлеген оештыру, аларны үзгәртеп кору һәм ябу тәртибе гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

26 статья. Өстәмә белем учреждениеләре

1. Өстәмә белем учреждениеләре гражданнарның белем һәм тәрбиягә булган шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларның үз белемнәрен күтәрү өчен хезмәт итә, һәм бу төзелмәләр мөстәкыйль рәвештә дә, шулай ук төп төзелмәләр белән бергәләп тә оештырылырга мөмкин.

Аларга исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана торган балалар өчен өстәмә белем учреждениеләре, шулай ук милли мәдәни үзәкләр, мәктәпләр, халык университетлары, лекторийлар, ата-аналар өчен мәктәпләр, төрле курслар һәм гыйльми-техник, икътисадый, эстетик, иҗтимагый-сәяси һәм башка белемнәрне пропагандалауның бүтән төрләре керә.

2. Өстәмә белем бирү учреждениеләренең тиешле рөхсәте (лицензиясе) булырга тиеш.

3. Мәгарифнең өстәмә төзелмәсенә керүче учреждениеләрне оештыру, финанслау һәм аларның эшчәнлек тәртибен гамәлгә куючылар билгели.

4. Өстәмә белем бирүче дәүләт учреждениеләре юридик зат булалар, аларның мөһере һәм мәгълүм үрнәктәге вывескасы була һәм үз эшчәнлекләрен устав нигезендә алып баралар.

27 статья. Белем турында документлар

1. Мәгариф учреждениесе лицензиясе нигезендә, йомгаклау аттестациясе узган затларга тиешле белеме һәм (яисә) белгечлеге турында документ бирә. Документ рәвеше мәгариф учреждениесенең үзе тарафыннан билгеләнә. Әлеге документлар мәгариф учреждениесе мөһере белән раслана.

2. Дәүләт аккредитациясе булган һәм гомуми белем (мәктәпкәчә яшьтәгедән тыш) һәм һөнәр белеме программаларын тормышка ашыручы гомуми, башлангыч һәм урта һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләре йомгаклау аттестациясе узган затларга тиешле

белем дәрәҗәсе һәм (яисә) белгечлеге турында дәүләт үрнәгендәге документ бирә.

3. Әгәр әлеге мәгариф учреждениесе уставында башкасы каралмаган булса, тиешле белеме һәм (яисә) белгечлеге турындагы документ югарырак дәрәҗәдәге дәүләт мәгариф учреждениесендә һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениесендә белем алуны дәвам итү өчен зарур шарт була.

Башлангыч һөнәр, урта һөнәр, югары һөнәр белеме һәм (яисә) белгечлеге турындагы документларда һәм югары уку йортыннан соңгы һөнәр белеме турындагы документларда күрсәтелгән гыйльми дәрәҗәләр аларга һөнәри эшчәнлек белән шөгыльләнергә, шул исәптән тиешле белем цензына билгеле бер тәртиптә мәҗбүри белгечлек таләпләре куелган урынны биләргә дә хокук бирә.

4. Татарстан Республикасында түбәндәге белем бирү дәрәҗәләре (белем бирү цензлары) билгеләнә:

1) төп гомуми (тулы булмаган урта) белем;
2) урта (тулы) гомуми белем;
3) башлангыч һөнәр белеме;
4) урта һөнәр белеме;
5) югары һөнәр белеме;
6) югары уку йортыннан соңгы һөнәр белеме.

5. Билгеле бер дәрәҗәдәге белем алуны төгәлләмәгән затларга тиешле үрнәктәге белешмә бирелә.

## Ш бүлек. Мәгариф системасы белән идарә итү

### 28 статья. Мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү

1. Мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне бүлешү һәм вәкаләтләрне алмашу турында" шартнамәсе, "Мәгариф турында" Россия Федерациясе Законы, әлеге закон, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында югары бе-

лем өлкәсендәге Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

29 статья. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы сәясәтен билгеләү;

- мәгариф әлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу, мәгариф өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп тору;

- мәгарифне үстерүнең комплексль дәүләт программаларын, мәгарифнең дәүләт стандартларының милли-төбәк компонентларын раслау;

- Татарстан Республикасы Республика бюджетының мәгариф чыгымнары өлешен, мәгариф үсеше фондларын раслау;

- республика керменең мәгарифне финанслауга юнәлтелүче өлешен билгеләү, финанслауның фәнни нигезләнгән дәүләт нормативларын, мәгариф үсешен кызыксындыручы салым ташламаларын билгеләү;

- мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының мактаулы исемнәрен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- мәгарифне үстерүнең Комплексль дәүләт программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

- мәгарифнең дәүләт стандартларының милли-төбәк компонентларын раслау;

- Татарстан Республикасының Мәгариф министрлыгы турындагы нигезләмәне, мәгариф учреждениеләре турындагы үрнәк нигезләмәләрне раслау;

- түбәндәгеләрне билгеләү:

а) мәгариф учреждениеләрен һәм мәгариф системасы оешмаларын финанслау тәртибен;

б) укучыларны, тәрбияләнүчеләрне, студентларны һәм мәгариф учреждениеләренең педагогия хезмәткәрләрен матди тәэмин итүнең нормаларын һәм төрләрен, шулай ук законнар нигезендә

ташламалар бирүне;

в) гражданнарга белем алу өчен дәүләт кредитын бирү һәм аны түләттерү тәртибен;

- республика буйсынуындагы башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме дәүләт учреждениеләрен, шулай ук махсус (коррекция) һәм башка мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм ябу;

- югары белем өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында төзелгән килешүне гамәлгә ашыру.

30 статья. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләре

1. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары гражданнарның әлеге Законда билгеләнгән мәҗбүри гомуми төп (тулы булмаган урта) белем алу хокукын гамәлгә ашыру өчен җаваплы була.

2. Халык депутатлары җирле Советларының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

а) законда билгеләнгән чикләрдә мәгариф мәсьәләләрен карау һәм хәл итү;

б) мәгариф үсеше программаларын раслау;

в) җирле бюджетның мәгариф чыгымнары өлешен, мәгарифне үстерү фондларын раслау, мәгарифне финанслауның җирле өстәмә нормативларын кабул итү;

г) үз вәкаләтләре чикләрендә мәгариф системасындагы милекчелек мөнәсәбәтләрен җайга салу;

д) районда, шәһәрдә мәгариф үсешен җайга салучы өстәмә салым ташламаларын законнар нигезендә билгеләү.

3. Җирле хакимиятнең мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

а) төрле типтагы балалар йортлары, мәктәп-интернатлар, ятимнәр һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен башка укыту-тәрбияләү учреждениеләре челтәрен үстерү, аларда балаларны укыту, тәрбияләү, аларны эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыру һәм укуларын дәвам итәргә булышу;

б) физик яктан һәм акыл ягыннан кимчелекле балаларны укы-

ту һәм тәрбияләүне, һөнәргә өйрәтүне, социаль-көнкүреш һәм матди яктан тәэмин итүне, аларга медицина хезмәте күрсәтүне һәм аларны дәвалауны камилләштерү буенча чаралар күрү;

в) мәктәпләрнең һәм мәктәптән тыш учреждениеләрнең укыту-җитештерү остаханәләрендә халык кулланувы товарларын җитештерүне оештыруны тәэмин итү, әлеге максатлардан чыгып, укучылар кооперативларын һәм башка хуҗалык берләшмәләрен киңәйтү;

г) дәүләт мәгариф идарәсенең җирле органнары эшчәнлеген тикшереп тору;

д) җирле бюджет проектын, мәгарифне финанслауның өстәмә җирле нормативларын әзерләү һәм аларны халык депутатлары Советы раславына тапшыру;

е) әлеге территориядә яшәүче гражданнарга гомуми белем бирү учреждениесен сайлау мөмкинлеген тәэмин итү;

ж) законнар нигезендә дәүләт мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм аларны ябу;

з) законнар нигезендә дәүләт мәгариф идарәсенең җирле органнарын төзү һәм ябу, аларның төзелмәләрен һөм вәкаләтләрен билгеләү, дәүләт мәгариф идарәсенең җирле органнары җитәкчеләрен билгеләп кую;

и) мәгариф учреждениеләрен педагогик кадрлар белән тәэмин итү, аларны социаль яклау буенча чаралар күрү;

к) балигъ булмаганнарга химаячелек (опека) һәм кайгыртуны (попечительлек) оештыру, аларның хокукларын яклау, ятимнәрне һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм булган балаларны балалар йортларына яисә интернат-мәктәпләргә урнаштыру, аларны тәрбияләү өчен гаиләләргә яисә уллыкка (кызлыкка) бирү;

л) балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтлекләрен саклау һәм җайга салу буенча максатчан гамәлләр кылу;

м) мәгариф учреждениеләренең биналарын һәм корылмаларын төзү, алар янындагы территорияләрне төзекләндерү;

н) мәгариф учреждениеләре биналарын, корылмаларын һәм аның милкендәге башка объектларны арендалау шартларын тикшереп тору;

о) дәүләт учреждениеләреннән, мәдәният һәм спорт объектларыннан мәгариф ихтыяҗларында файдалану;

п) укыту-тәрбияләү учреждениеләре коллективлары белән килешеп, мәгариф хезмәткәрләрен дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү.

4. Җирле үзидарәнең тиешле органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

а) җирле бюджетларның мәгариф чыгымнары өлешен оештыру;

б) балигъ булмаганнарның хокукларын яклау, балалар бакчалары, мәктәп-интернатлар челтәрен үстерү;

в) мәгариф учреждениеләре биналарын һәм корылмаларын төзү, аның территориясен төзекләндерү;

г) укучыларны, тәрбияләнүчеләрне укыту һәм тәрбияләүне, һөнәргә өйрәтүне, социаль-көнкүреш һәм матди яктан тәэмин итүне, аларга медицина хезмәте күрсәтүне, аларны дәвалауны камилләштерү буенча чаралар күрү;

д) мәктәпләрнең һәм мәктәптән тыш учреждениеләрнең укыту-җитештерү остаханәләрендә халык кулланулы товарларын җитештерүне оештыруны тәэмин итү.

<u>31 статья.</u> Мәгариф белән дәүләт идарәсенең вәкаләтле органнары

1. Мәгариф белән дәүләт идарәсе органнары башкарма хакимиятнең тиешле органы карары белән дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) тиешле органы белән килешеп төзелә.

2. Мәгариф идарәсенең дәүләт органы вәкаләтенә түбәндәгеләр керә:

а) мәгарифне үстерү программалары эшләү һәм тормышка ашыру;

б) дәүләт белем бирү стандартларының милли төбәк компонентларын раслау;

в) үз вәкаләтләре чикләрендә мәгариф учреждениеләрен лицензияләү һәм дәүләт аккредитацияләве;

г) төрле типтагы һәм төрдәге мәгариф учреждениеләре педагогия хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибен һәм әлеге педагогия хезмәткәрләренең белем бирү цензларына таләпләр билгеләү;

д) мәгариф системасы төзелмәләрен оештыру; һөнәр әзерлеге һәм һөнәр белем бирүе алып барылучы һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеген эшләү;

е) алар тарафыннан гамәлгә куелган мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген турыдан-туры финанслау;

ж) мәгариф системасын үстерүнең һәм тотрыкландыруның дәү-

ләт фондларын булдыру;

з) мәгариф учреждениеләрен финанслауның дәүләт нормативларын, шулай ук белем бирү барышының матди техник тәэмин ителешен һәм коралланышын финанслау нормативларын эшләү;

и) мәгариф учреждениеләре челтәре үсешен фаразлау, төбәкләрдә мәгарифне үстерү ихтыяҗларына бюджеттан максатчан субвенцияләр бүлеп бирү тәкъдимнәре әзерләү;

к) мәгариф өлкәсендә законнарның, дәүләт белем бирү стандартларының үтәлешен, мәгариф системасында бюджет һәм финанс дисциплинасын тикшереп тору.

3. Мәгарифкә идарә итү органнары тикшерүендә алар буйсынуындагы белем бирү учреждениеләре була. Мәгариф учреждениесе мәгариф өлкәсендәге законнарны һәм (яисә) үзенең уставын бозу очракларында мәгарифкә идарә итү дәүләт органы үз боерыгы белән мәгариф учреждениесе эшчәнлеген суд карарына кадәр туктатып торуга хаклы.

<u>32 статья.</u> Мәгариф учреждениесенең вәкаләтләре һәм җаваплылыгы

1. Мәгариф учреждениесе укыту гамәлләрен башкаруда, кадрларны сайлау һәм урнаштыруда, фәнни, финанс, хуҗалык эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне башкаруда законнарда һәм мәгариф учреждениесе уставында билгеләнгән кысаларда мөстәкыйль эш итә.

2. Мәгариф учреждениесе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

а) банк кредитларыннан файдалануны да кертеп, өстәмә финанс чыганакларын һәм матди чараларны уставта күрсәтелгән эшчәнлекне башкару өчен җәлеп итү;

б) акчалар керү һәм аларны тоту турында гамәлгә куючы һәм җәмәгатьчелек каршында ел саен хисап тоту;

в) педагогия кадрларын һәм ярдәмче персоналны сайлап алу, эшкә кабул итү һәм урнаштыру;

г) укыту барышын ысулый тәэмин итүне оештыру һәм камилләштерү;

д) Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының база планы буенча укыту программаларын, уку планнарын эшләү һәм раслау;

е) уку курслары һәм фәннәрнең эш программаларын әзерләү

һәм раслау;

ж) уку барышының еллык графикларын эшләү һәм раслау;

з) мәгариф учреждениесе эшчәнлегенә идарә итү төзелмәсен, штатлар расписаниесен билгеләү, эш вазыйфаларын бүлү;

и) хезмәт хакына өстәлмәләрне һәм өстәмә түләүләрне, хезмәткәрләрне бүләкләү тәртибен һәм күләмнәрен билгеләү;

к) мәгариф учреждениесе уставын әзерләү;

л) мәгариф учреждениесенең эчке тәртип кагыйдәләрен, башка локаль актларны әзерләү һәм кабул итү;

м) әгәр уртак нигезләмәдә һәм әлеге Законда мәгариф учреждениесенең шушы төре һәм рәвеше турында башкасы каралмаган булса, лицензиядә күрсәтелгән квота чикләрендә укучылар һәм тәрбияләнүчеләр контингентын мөстәкыйль оештыру;

н) мәгариф учреждениесе уставы,лицензия һәм дәүләт аккредитациясе турындагы таныклык нигезендә белем бирү гамәлләрен мөстәкыйль башкару;

о) үз уставы һәм әлеге Законда куелган таләпләр нигезендә укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең өлгерешен һәм арадаш аттестацияләнүен тикшереп тору;

п) укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең аерым категорияләренә законнарда, шулай ук дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары актларында каралган өстәмә ташламалар һәм матди тәэминат төрләрен вакытында бирүне тикшереп тору;

р) укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең мәгариф учреждениеләрендә кайнар азык белән туклануын, аларга медицина хезмәте күрсәтүне, аларны дәвалауны оештыру өчен шартлар тудыру;

с) мәгариф учреждениесендә җәмәгать (шул исәптән балалар һәм яшьләр) берләшмәләренең законда рөхсәт ителгән эшчәнлеген җайга салу;

т) законнарда тыелмаган һәм мәгариф учреждениесе уставында каралган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру.

у) интернат үрнәгендәге мәгариф учреждениесендә тәрбияләнүчеләрне тотуның нормативтан түбән булмаган шартларын тәэмин итү;

ф) укытучылар (педагоглар) оешмалары һәм методик берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итү.

3. Мәгариф учреждениесе законнарда билгеләнгән тәртиптә

түбәндәгеләр өчен җаваплы була:

а) белем бирү барышында укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомере һәм сәламәтлеге өчен;

б) укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең һәм мәгариф учреждениесе хезмәткәрләренең хокукларын һәм ирекләрен бозган өчен;

в) үз вәкаләтләрендәге вазыйфаларны үтәмәгән өчен;

г) уку планы һәм укыту графигы нигезендә уку-укыту программаларын тулысынча гамәлгә ашырмаган өчен, үзләрендә укып чыкканнарның белем сыйфаты өчен;

д) законнарда каралган башка гамәлләр өчен.

33 статья. Дәүләт мәгариф учреждениеләре һәм җирле үзидарә учреждениеләре белән идарә итү

1. Дәүләт мәгариф учреждениеләре һәм җирле үзидарә учреждениеләре белән идарә итү Татарстан Республикасы законнары һәм мәгариф учреждениесе уставы нигезендә берлек һәм үзидарә принципларында гамәлгә ашырыла.

2. Мәгариф учреждениесенең үзидарә рәвешләре булып: мәгариф учреждениесе советы, попечительләр советы, гомуми җыелыш, педагогия советы һәм башка рәвешләр тора.

3. Мәгариф учреждениесе белән аның директоры, мөдире, ректоры яисә башка җитәкчесе турыдан-туры идарә итә.

Дәүләт мәгариф учреждениесе һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениесе җитәкчесе устав нигезендә:

а) мәгариф учреждениесе коллективы тарафыннан сайлана ала;

б) кандидатураны (кандидатураларны) гамәлгә куючы белән алдан килештереп, мәгариф учреждениесе коллективы тарафыннан сайлана ала;

в) гамәлгә куючы тарафыннан аннары расланып, мәгариф учреждениесе коллективы тарафыннан сайлана ала;

г) мәгариф учреждениесе советына "вето" хокукы биреп, гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнеп куела ала;

д) гамәлгә куючы тарафыннан яллана ала.

Югары һөнәр белем бирү учреждениеләрендә ректорлар билгеләүгә юл куелмый.

4. Мәгариф учреждениесе советы белән мәгариф учреждениесе җитәкчесе арасында вәкаләтләрне бүлешү мәгариф учреждениесе уставында билгеләнә.

5. Дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениеләренең җитәкчеләренә мәгариф учреждениеләренең үзендә яисә алардан читтә бүтән (фәнни һәм фәнни-ысулый җитәкчелектән гайре) җитәкче вазыйфаларын башкару рөхсәт ителми.

6. Дәүләт мәгариф учреждениеләренең, аларның филиалларының (бүлекчәләренең) җитәкчеләре бер үк вакытта ике урындагы хезмәт вазыйфаларын башкара алмыйлар.

<u>34 статья.</u> Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре белән идарә итү

1. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениесе белән җитәкчелекне турыдан-туры аны гамәлгә куючы яисә аның кушуы буенча гамәлгә куючы төзегән попечительләр советы тормышка ашыра.

2. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениесе идарәсенең эчке схемасы һәм попечительләр советы вәкаләтләре, шулай ук әлеге мәгариф учреждениесе җитәкчесен билгеләү яисә сайлау процедурасы һәм әлеге җитәкченең вәкаләтләре бу мәгариф учреждениесен гамәлгә куючы (попечительләр советы) тарафыннан педагогия коллективы белән килешенеп билгеләнә һәм дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениесе уставында беркетелә.

<u>35 статья.</u> Мәгариф учреждениесен төзү, үзгәртеп кору һәм ябу тәртибе

1. Мәгариф учреждениесе гамәлгә куючы тарафыннан үз инициативасы белән төзелә һәм гариза кертү тәртибендә законнар нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан теркәлә.

2. Мәгариф учреждениесен теркәүдә максатка яраксыз дигән дәлилләр кулланып баш тартырга тиеш түгелләр. Теркәүдән баш тарту, шулай ук алардан тайпылырга тырышу турында гамәлгә куючы судка шикаять бирә ала.

3. Мәгариф учреждениесенең үз уставында каралган һәм белем бирүне оештыруга юнәлдерелгән финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып бару өлешендәге юридик зат хокуклары мәгариф учреждениесен теркәү мизгеленнән башлана.

4. Мәгариф учреждениесенең мәгариф эшчәнлеген алып бару хокукы һәм законнарда билгеләнгән ташламалар аңа рөхсәт (лицензия) биргән мизгелдән башлана.

5. Мәгариф эшчәнлеген алып бару хокукына лизенция законнар нигезендә, эксперт комиссиясе бәяләмәсе нигезендә дәүләт мәгариф идарәсе органы тарафыннан бирелә. Дини берләшмәләрнең мәгариф учреждениеләренә мәгариф эшчәнлеге алып бару өчен лицензия тиешле конфессия җитәкчелеге тәкъдиме буенча бирелә.

6. Эксперт комиссиясе дәүләт мәгариф идарәсе органы тарафыннан төзелә. Эксперт комиссиясенә бертигез хокукларда дәүләт мәгариф идарәсе органы вәкиләре, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле җирле органы, җирле үзидарә органы вәкилләре һәм гамәлдәге мәгариф учреждениеләре вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре керә.

7. Оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, мәгариф учреждениеләре тарафыннан лицензия шартларының үтәлешен тикшереп торуны дәүләт мәгариф идарәсе органы тәэмин итә. Лицензиянең билгеләнгән шартлары бозылганда, ул кире алынырга тиеш. Лицензияне яңарту аны алгандагы кебек үк тәртиптә башкарыла.

8. Дәүләт мәгариф учреждениесенең аны тәмамлаучыларга тиешле белем һәм (яисә) квалификация турында документ бирү хокукы, шулай ук дәүләт финанслау системасына керү хокукы аны дәүләт аккредитацияләве мизгеленнән башлана.

9. Мәгариф учреждениесен дәүләт аккредитацияләве турындагы таныклык аның дәүләт статусын, гамәлгә ашырылучы белем бирү программалары дәрәҗәсен, чыгарылучыларны әзерләү эчтәлеге һәм сыйфатының дәүләт белем бирү стандартларына туры килүен, чыгарылучыларга белемнәрнең тиешле дәрәҗәсе турында дәүләт үрнәгендәге документ бирү хокукын раслый.

Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә һәм балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренә бирелүче дәүләт аккредитацияләве турындагы таныклык әлеге белем бирү учреждениесенең дәүләт статусын, ул гамәлгә ашыручы белем бирү программаларының дәрәҗәсен, бу мәгариф учреждениясенең категориясен раслый.

10. Мәгариф учреждениеләрен дәүләт тарафыннан аккредитацияләүне мәгариф учреждениесе гаризасы һәм аны аттестацияләү бәяләмәсе нигезендә дәүләт мәгариф идарәсе органнары башкара.

11. Мәгариф учреждениесен аттестацияләү, әйдәүче мәгариф

учреждениеләрен, җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, аның үз гаризасы буенча дәүләт мәгариф идарәсе органнары тарафыннан уздырыла. Әгәр законда башкасы каралмаса, аттестация биш елга бер тапкыр үткәрелә.

12. Аттестацияләүнең максаты мәгариф учреждениесен тәмамлаучыларны әзерләү эчтәлегенең, дәрәҗәсенең һәм сыйфатының дәүләт мәгариф стандартлары таләпләренә туры килү-килмәвен билгеләүдән гыйбарәт. Мәгариф учреждениесен аттестацияләүнең шарты - аны тәмамлаучыларның кимендә яртысы өч ел рәттән йомгаклау аттестациясендә уңай нәтиҗәләргә ирешергә тиеш.

Яңа оештырылган мәгариф учреждениесен беренче тапкыр аттестацияләү аның үз гаризасы буенча анда укучыларның беренче чыгарылышыннан соң, әмма рөхсәт (лицензия) алганнан соң кимендә өч ел үткәч уздырылырга тиеш.

13. Мәгариф учреждениесе аттестация нәтиҗәләре буенча дәүләт аккредитациясеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

14. Мәгариф учреждениеләре филиаллары (бүлекчәләре) хакыйкый адреслары буенча теркәләләр, әлеге Закон белән мәгариф учреждениеләре өчен билгеләнгән гомуми тәртиптә лицензияләнәләр, аттестацияләнәләр һәм дәүләт аккредитациясен алалар.

15. Мәгариф учреждениесе гамәлгә куючы карары буенча законнар нигезендә башка төрле мәгариф учреждениесенә үзгәртеп корылырга мөмкин.

16. Мәгариф учреждениесен үзгәртеп корганда, аның уставы, лицензиясе һәм дәүләт аккредитациясе турындагы таныклыгы үз көчләрен югалталар.

17. Республика мәгариф учреждениеләрен дәүләт идарәсенең җирле органнары карамагына тапшыруга аларның үз ризалыгы булганда гына юл куела.

18. Мәгариф учреждениесен ябу түбәндәгечә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- аны гамәлгә куючының яисә гамәлгә кую документлары нигезендә вәкаләт бирелгән юридик зат органының карары буенча;

- тиешле рөхсәтсез (лицензиясез) килеш, законда тыелган йә аның устав максатларына туры килмәгән эшчәнлек алып барган очракта, шулай ук законда каралган башка очракларда хөкем карары буенча.

19. Мәктәпкәчә авыл мәгариф учреждениесен яисә гомуми бе-

лем бирү учреждениесен ябу бары тик әлеге учреждениеләр хезмәт күрсәтә торган торак пунктлары халкының җыены рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

IV бүлек. Мәгариф системасы икътисады

36 статья. Мәгариф системасында милек мөнәсәбәтләре

1. Гамәлгә куючы мәгариф учреждениесенә, аның үз уставындагы мәгариф эшчәнлеген тәэмин итү йөзеннән, гамәлгә куючының милкендә булган биналарны, корылмаларны, мөлкәт комплексларын, җиһазларны, шулай ук кулланылышта, социаль, мәдәни һәм башка ихтыяҗлар өчен кирәкле мөлкәтне оператив идарәсе итүгә беркетә.

Җир кишәрлекләре дәүләт мәгариф учреждениеләренә һәм җирле үзидарә мәгариф учреждениесенә чикләнмәгән вакытка, түләүсез куллану өчен беркетелә.

2. Мәгариф учреждениесе милекче алдында үзенә беркетелгән мөлкәтнең сакланышы һәм аннан нәтиҗәле файдалану өчен җаваплы була. Мәгариф учреждениесенең бу өлкәдәге эшчәнлеген милекче тикшереп тора.

3.Мәгариф учреждениесенә беркетелгән мөлкәт законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда милекче тарафыннан тартып алынырга мөмкин.

4. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениесе, элегрәк үзенең оператив идарәсенә беркетелгән яисә арендага алынган дәүләт милкендәге хосусыйлаштырылучы мөлкәтне сатып алу буенча өстенлекле хокукка ия.

5. Мәгариф учреждениесе үзенә физик һәм хокукый затлар тарафыннан бүләк, иганә һәм васыять итеп бирелгән акчага, мөлкәткә һәм башка милек объектларына, аның эшчәнлегенең нәтиҗәсе булган рухи һәм иҗади хезмәт җимешләренә, шулай ук мәгариф учреждениесенең үз эшчәнлегеннән килгән керемнәргә һәм әлеге керемнәргә сатып алынган мөлкәткә карата милекчелек хокукына ия була.

6. Дәүләткә карамаган мәгариф оешмасы законда билгеләнгән нигезләрдә бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылырга мөмкин.

7. Мәгариф учреждениесе үз йөкләмәләре буенча закон ниге-

зендә җавап бирә. Мәгариф учреждениесенең акчасы җитәрлек булмаганда, гамәлгә куючы законда билгеләнгән тәртиптә аның йөкләмәләре өчен җаваплы була.

8. Әгәр мәгариф учреждениесен гамәлгә куючы һәм аңа беркетелгән мөлкәтнең милекчесе дәүләт хакимияте һәм идарәсенең шул ук административ-территория берәмлегендәге җирле органнары булса, беркетелгән милек объектларыннан файдаланган өчен аренда түләве алынмый, ә агымдагы чыгымнар, капиталь ремонт өчен һәм тиешле мәгариф учреждениесен тоту өчен чыгымнарны, гамәлгә куючы белән мәгариф учреждениесе арасында төзелгән шартнамәдә башкасы каралмаган булса, гамәлгә куючы (милекче) каплый.

9. Дәүләт мәгариф учреждениеләре һәм оператив идарә итү хокукында аларга беркетелгән яисә аларның мөстәкыйль карамагында булган җитештерү һәм социаль инфратөзелмә объектлары хосусыйлаштырылмый.

<u>37 статья.</u> Мәгариф учреждениеләрен финанслау

1. Мәгариф учреждениесенең эшчәнлеге аның гамәлгә куючысы тарафыннан алар арасында төзелгән шартнамә нигезендә финанслана. Гамәлгә куючы белән мәгариф учреждениесе арасында төзелгән шартнамә буенча соңгысы үз-үзен финанслау шартларында эшләргә мөмкин.

2. Мәгариф учреждениеләре һәр аерым төрдәге, типтагы һәм категориядәге мәгариф учреждениесе буенча бер укучыга, тәрбияләнүчегә исәпләнеп билгеләнүче тиешле финанслау нормативлары нигезендә Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана.

Авыл җирендәге аз комплектлы һәм дәүләт идарәсе органнары, дәүләт мәгариф идарәсе органнары тарафыннан шуларга тиңләштерелгән мәгариф учреждениеләре өчен финанслау нормативы белем алучыларның санына бәйле булмаган чыгымнарны исәпкә алырга тиеш.

Югары һәм урта һөнәр белеме бирү учреждениеләрен финанслау Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан һәм федераль бюджеттан югары белем өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре арасында төзелгән килешүдә билгеләнә торган өлешләрдә алып барыла.

3. Мәгариф учреждениеләрен финанслауның республика нормативлары чираттагы һәр елга закон тарафыннан билгеләнә.

4. Финанслауның республика һәм җирле нормативлары мәгариф учреждениесенең үзенчәлекләрен исәпкә алырга тиеш һәм укыту барышына, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә бәйле һәм мәгариф учреждениесен тиешенчә җиһазландыру исемлегенә шушы территория буенча каралган агымдагы уртача чыгымнарны каплау өчен җитәрлек булырга тиеш.

5. Дәүләт мәгариф учреждениеләрен финанслау системасы тиешле типтагы һәм төрдәге мәгариф учреждениеләре турындагы үрнәк нигезләмәләр белән билгеләнә.

6. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативлары әлеге төбәктәге шундый ук дәүләт һәм җирле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларыннан түбән була алмый.

7. Мәгариф учреждениеләре, оешу-хокукый рәвешләренә карамастан, законнарда билгеләнгән тәртиптә өстәмә финанс чыганакларын җәлеп итәргә хаклы.

Мәгариф учреждениеләренең һәм оешмаларының өстәмә финанс чыганаклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) кадрлар әзерләү һәм аларның белгечлекләрен күтәрү буенча хезмәт күрсәткән өчен министрлыклардан, дәүләт комитетларыннан һәм ведомстволардан, оешмалардан, шулай ук чит ил оешмаларыннан кергән акчалардан;

б) уку йортлары продукцияләрен сатудан, биналарны һәм җайланмаларны закон нигезендә арендага тапшырудан, кулланылмый торган җайланмаларны сатудан алынган акчалардан;

в) хөкүмәтара килешүләр нигезендә башка республикалардан килгән бюджет кертемнәреннән;

г) мәгариф мәнфәгатьләре өчен законнар нигезендә билгеләнә торган максатчыл җыемнардан;

д) дәүләт, иҗтимагый һәм башка предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан, шулай ук аерым гражданнардан кергән ирекле кертемнәрдән, иганәләрдән һәм тапшырылган матди байлыклардан;

е) башка керемнәрдән, шул исәптән түләүле төрле хезмәт күрсәтү өчен керемнәрдән.

Акчаларның өстәмә чыганакларын җәлеп итү мәгариф учрежде-

ниесен гамәлгә куючылар исәбеннән финанслауның нормативларын һәм абсолют күләмнәрен киметүгә китерми.

8. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениеләре, үзләренең төп мәгариф программаларын үтәгән очракта, дәүләт аккредитацияләве алган мизгелдән дәүләт тарафыннан финанслау хокукына ия булалар.

9. Башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме бирү учреждениеләре укучыларны укырга алу буенча гамәлгә куючы акчалары исәбеннән финансланучы йөкләмәләрдән (контроль саннардан) тыш, квалификацияле эш хезмәткәрләрен һәм белемнәре әлеге дәрәҗәдәге белгечләре әзерләүне һәм яңа һөнәргә өйрәтүне физик һәм (яисә) юридик затлар белән төзелгән шартнамәләр буенча, алардан укыту бәясен түләтеп, гамәлгә ашыруга хокуклы.

38 статья. Мәгарифне дәүләт тарафыннан кызыксындыру

1. Татарстан Республикасы гражданнарының дәүләт мәгариф стандартлары кысаларында белем алуга дәүләт гарантиясе нигезе булып мәгарифне дәүләт тарафыннан финанслау тора.

2. Дәүләт мәгариф ихтыяҗлары өчен ел саен финанс акчалары бүлеп бирүне, шулай ук тиешле бюджетларның тиешле чыгымнар статьяларының яклanылышын гарантияли. Тәгәл сумма ел саен Татарстан Республикасы Республика бюджетын һәм җирле бюджетларны раслаганда билгеләнә. Мәгариф учреждениеләрен финанслауның күләмнәре һәм нормативлары, инфляция үсеше темпыннан чыгып, индексацияләнергә тиеш.

3. Мәгариф учреждениеләре үзләренең уставларында каралган һәм эшкуарлыкка карамаган эшчәнлек өлешендә законнар билгеләгән тәртиптә салым түләүләреннән азат ителәләр.

4. Мәгариф системасына инвестицияләр тарту максатларында үз байлыкларын, шул санда натураль рәвештә Татарстан Республикасы мәгариф системасын үстерүгә биргән предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга, аларның оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, шулай ук физик затларга, шул санда чит ил гражданнарына салым ташламаларының махсус системасын күздә тота. Мондый ташламаларның характеры, күләмнәре һәм аларны бирү тәртибе законнар белән билгеләнә.

5. Укыту-тәрбияләүне оештыру өчен мәгариф учреждениеләре-

нә мөлкәтләрен бөтенләйгә бушлай бирүче төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, законнар нигезендә мөлкәткә салым түләүдән азат ителергә мөмкин.

6. Балигъ булмаган баланы гаиләдә тәрбияләүче һәм аңа белем бирүче ата-аналарга (аларның законлы вәкилләренә) дәүләт мәгариф учреждениесендә тиешле этапта бер баланы укыту өчен финанслауның дәүләт нормативлары белән билгеләнүче чыгымнар күләмендә өстәмә акча түләнә. Бу түләүләр тиешле төрдәге һәм рәвештәге мәгариф учреждениеләренең гамәлгә куючысы акчалары исәбеннән бала гомуми урта (тулы) яисә башлангыч һөнәр белеме алганчыга кадәр, йә балаларның социаль түләүләр өчен законнарда билгеләнгән яше җиткәнче башкарыла.

7. Дәүләт балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре челтәрен үстерү өчен кирәкле шартлар тудыра һәм бу учреждениеләргә матди ярдәм, шул исәптән финанс ярдәме күрсәтә.

<u>39 статья.</u> Мәгариф учреждениеләренең матди-техник нигезе

1. Мәгариф учреждениесе үзенә оператив идарәгә беркетелгән һәм (яисә) үз милкендә булган мөлкәтне Татарстан Республикасында гамәлдә булган нормативларда билгеләнгән дәрәҗәдән дә түбән тотмауны тәэмин итәргә бурычлы.

2. Дәүләт мәгариф учреждениесенең матди-техник базасын үстерү үзенә беркетелгән бюджет акчалары һәм үз акчалары кысаларында мәгариф учреждениесенең үзе тарафыннан башкарыла.

3. Мәгарифкә идарәнең дәүләт органнары мәгариф учреждениеләренең матди-техник базасын үстерү һәм аны тоту мәсьәләләрен хәл итүдә катнашырга бурычлы.

<u>40 статья.</u> Мәгариф учреждениесенең финанс һәм матди байлыклардан файдалану хокуклары

1. Мәгариф учреждениесе финанс-хуҗалык эшчәнлеген мөстәкыйль алып бара. Аның банк һәм башка кредит оешмаларында мөстәкыйль балансы һәм исәп-хисап счеты, шул исәптән валюта счеты да була.

2. Мәгариф учреждениесе милкендә булган яисә гамәлгә куючы тарафыннан аңа беркетелгән финанс һәм матди чараларны ул,

мәгариф учреждениесе уставы нигезендә үзе теләгәнчә куллана ала һәм, законнарда башкасы каралмаган булса, бу чаралар тартып алынмый.

3. Агымдагы елда (кварталда, айда) кулланылмый калган финанс чаралары мәгариф учреждениесеннән гамәлгә куючы тарафыннан тартып алынмый яисә әлеге мәгариф учреждениесен киләсе елга (кварталга, айга) финанслауда гамәлгә куючы тарафыннан исәпкә кертелә алмый.

4. Мәгариф учреждениесе хуҗалык ширкәтләренең, җәмгыятьләренең һәм башка оешмаларның устав фондларында тик үз милке хокукындагы үз мөлкәте белән генә катнашырга хаклы.

5. Мәгариф учреждениесе милекчесе ризалыгы белән үзенә беркетелгән финанс чараларын һәм башка мөлкәтне керем алу белән бәйле эшчәнлегендә файдаланырга хаклы. Бу очракта милекче үзенә беркетелгән милек объектларыннан файдаланудан килгән керемнең милекче белән мәгариф учреждениесе арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнгән күләмдәге өлешенә хокук ала.

<u>41 статья.</u> Дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм җирле үзидарә органнары мәгариф учреждениеләренең түләүле өстәмә мәгариф хезмәте күрсәтүләре

1. Дәүләт мәгариф учреждениеләре һәм җирле үзидарәләр мәгариф учреждениеләре халыкка, предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга тиешле мәгариф программаларында һәм дәүләт мәгариф стандартларында каралмаган түләүле түбәндәге өстәмә хезмәтләрне күрсәтергә хаклы:

- аерым фәннәрне яисә фәннәр циклын укыту;
- фәннәрне тирәнтен өйрәтү;
- абитуриент сыйныфлары, әзерлек курслары, түгәрәкләр һәм секцияләр оештыру;
- консультация хезмәте күрсәтү;
- репетиторлык;
- башка мәгариф хезмәте күрсәтүләр.

2. Түләүле өстәмә хезмәт күрсәтүләр бюджеттан финансланучы төп мәгариф эшчәнлеге урынына башкарылырга тиеш түгел.

Юкса, тиешле финанс акчалары гамәлгә куючы тарафыннан аның бюджетына кире кайтарып алына.

3. Мәгариф учреждениесенең түләүле өстәмә белем бирү хезмәт күрсәтүләреннән килүче керем шушы мәгариф учреждениесенә яңадан инвестицияләнә, шул исәптән, ул үзе кирәк дип тапса, хезмәт хакы чыгымнарын арттыру өчен дә тотылырга мөмкин. Мондый эшчәнлек эшкуарлык эшчәнлегенә кертелми.

<u>42 статья.</u> Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениесенең түләүле мәгариф эшчәнлеге

1. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениесе белем биргән өчен, шул исәптән мәгарифнең дәүләт стандартлары кысаларында белем биргән өчен белем алучылардан, тәрбияләнүчеләрдән түләү алырга хаклы.

2. Әгәр түләүле мәгариф эшчәнлегеннән килә торган керем тулысынча әлеге мәгариф учреждениесендә белем бирүне тәэмин итү буенча чыгымнарны каплауга (шул исәптән хезмәт хакы түләүгә), аны үстерүгә һәм камилләштерүгә китсә, мондый эшчәнлек эшкуарлык эшчәнлеге дип саналмый.

3. Дәүләткә карамаган мәгариф учреждениесе белән укучы, тәрбияләнүче, аның ата-аналары (аларның законлы вәкилләре) арасындагы үзара мөнәсәбәтләр белем бирү дәрәҗәсен, белем бирү вакытларын, белем алу өчен түләү күләмнәрен, башка шартларны билгеләүче шартнамә нигезендә җайга салына.

<u>43 статья.</u> Сыйфатсыз белем биргән өчен китерелгән зыянны каплау

1. Аккредитацияләнгән мәгариф учреждениесендә белем алып чыгучыларга сыйфатсыз белем бирелгәнлеге мәгълүм булса, мәгарифкә дәүләт идарәсе органнары укуны тәмамлаучыларны башка мәгариф учреждениеләрендә яңадан укытуга тотылган өстәмә чыгымнарны каплау хакында әлеге белем бирү учреждениесенә дәгъва белдерергә хаклы.

2. Татарстан Республикасының дәүләт аттестация хезмәтенең һәм мәгарифкә дәүләт идарәсе органнарының укуны тәмамлаучыларның әзерлек сыйфатына рекламациясе дәгъва белдерү өчен нигез булып тора.

44 статья. Мөгариф учреждениесенең эшкуарлык эшчәнлеге

1. Мәгариф учреждениесе үзенең уставында каралган эшкуарлык эшчәнлеген законнарда билгеләнгән тәртиптә алып барырга хаклы.

2. Мәгариф учреждениесенең эшкуарлык эшчәнлеге аның уставында каралган мәгариф эшчөнлегенә зыян китерә торган булса, әлеге мәсьәлә буенча хөкем карары чыгарылганчы, гамәлгә куючы яисә мәгарифкә дәүләт идарәсенең җирле органнары аның бу эшчәнлеген туктатып торырга хаклы.

3. Бу мәгариф учреждениесе уставында каралган җитештерелгән продукцияне, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне сату буенча бу мәгариф учреждениесенең эшчәнлеге, әлеге эшчәнлектән алынган керемнең бу мәгариф учреждениесенә турыдан-туры яңадан инвестицияләнмәгән һәм (яисә) бу мәгариф учреждениесендә белем бирү барышын тәэмин итүнең, үстерүнең һәм камилләштерүнең турыдан-туры ихтыяҗларына тотылмаган өлеше генә эшкуарлык эшчәнлегенә кертелә.

## V бүлек. Мәгарифнең социаль якланышы

45 статья. Укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең хокуклары һәм социаль якланышы

1. Укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары Татарстан Республикасы законнары һәм мәгариф учреждениесе уставы белән билгеләнә.

2. Барлык мәгариф учреждениеләре укучылары гамәлдәге законнар нигезендә түбәндәгеләргә хаклы:

- дәүләт мәгариф стандарты нигезендә белем алырга;
- белем алу йортын, белем алу телен, белем алу юнәлешен һәм рәвешләрен, шәхси программаларны сайларга;
- түләүле өстәмә мәгариф хезмәте күрсәтүләрдән файдаланырга;
- белем алу чорын киметергә, барлык яисә кайбер фәннәрдән экстерн рәвешендә имтиханнар бирергә;
- үз карашларын һәм фикерләрен ирекле белдерергә;
- укыту-тәрбия барышында каралган гамәлләрне уздырганда

укыту-тәрбия учреждениесенең фәнни, укыту-җитештерү, мәдәни-спорт һәм савыктыру базасыннан бушлай файдаланырга;

- фәнни эштә, уйлап табу һәм рационализаторлык эшчәнлегендә катнашырга, чит илләргә укырга стажировкага җибәрелергә, конференцияләрдә, олимпиадаларда һәм башка мәгариф чараларында катнашырга;

- белем алуын дәвам итәргә;

- укучы, тәрбияләнүче абруен һәм намусын кимсетүче администрациянең, укытучыларның гамәлләре хакында укыту-мәгариф учреждениесе советына шикаять белдерергә, үзенә кешелекле, гадел мөнәсәбәт таләп итәргә.

3. Дәүләт мәгариф учреждениесендә яисә җирле үзидарә мәгариф учреждениесендә укучыларны, тәрбияләнүчеләрне гамәлгә куючы үз вәкаләте чикләрендә һәм гамәлдәге нормативлар нигезендә стипендияләр, тулай торакларда һәм интернатларда урыннар, ташламалы яисә түләүсез туклану һәм транспортта йөрү, башка төр ташламалар һәм матди ярдәм белән тәэмин итә.

4. Укучыларны, тәрбияләнүчеләрне иҗтимагый берләшмәләргә мәҗбүри рәвештә кертү, шулай ук әлеге берләшмәләрнең эшчәнлегендә, үгетләү кампанияләрендә һәм сәяси гамәлләрдә катнашуга көчләп җәлеп итү тыела.

5. Мәгариф учреждениеләрендә хезмәттән аерылып һәм аерылмыйча (кичке) һәм хезмәттән аерылмыйча укып, уку планын үтәүчеләр кыскартылган эш атнасына, эш урыны буенча өстәмә түләүле ялга һәм законнарда каралган тәртиптә бирелүче башка ташламаларга хокуклы.

6. Ятим балаларны һәм ата-анасыз (законлы вәкилләрсез) калган балаларны дәүләтнеке булган һәм дәүләткә карамаган аккредитацияләнгән мәгариф учреждениеләрендә укыту һәм тоту тулысынча дәүләт тәэминаты нигезендә башкарыла.

7. Акыл ягыннан һәм физик яктан зәгыйфь балалар һәм яшүсмерләр өчен мәгарифкә идарәнең җирле органнары аларны тәрбияләүне, укытуны, дәвалауны, социаль адаптацияне һәм җәмгыятькә керүләрен тәэмин итүче төркемнәр, махсус (коррекцияләнгән) сыйныфлар, мәгариф учреждениеләре оештыралар. Әлеге категория укучыларны, тәрбияләнүчеләрне мондый төркемнәргә, сыйныфларга, учреждениеләргә җибәрү бары тик психологик-медик-педагогик комиссияләрнең бәяләмәләре буенча, ата-аналарының (законлы вә-

246



килләренең) фикерләрен исәпкә алып кына башкарыла. Күрсәтелгән мәгариф учреждениеләрен финанслау Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган нормативлар буенча гамәлгә ашырыла.

8. Унбер яшенә җиткән, аерым шартларда тәрбияләнүгә һәм укуга мохтаҗ булган һәм махсус педагогик алымнарны куллануны сорый торган девиант (җәмгыять өчен куркыныч) тәртипле яшүсмерләр өчен махсус укыту-тәрбия учреждениеләре булдырыла, әлеге учреждениеләр яшүсмерләрнең медицина һәм социаль яктан реабилитацияләнүләрен, белем алуларын һәм һөнәргә әзерлекләрен тәэмин итә.

Мондый мәгариф учреждениеләренә укучылар бары тик суд карары нигезендә генә җибәреләләр.

9. Аеруча сәләтле балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр өчен махсус мәгариф учреждениеләре оештырылырга мөмкин. Әлеге төр мәгариф учреждениеләренә укучыларны сайлап алу критерийлары гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә җиткерелә.

Мондый мәгариф учреждениеләрен нормадан тыш финанслау гамәлгә куючы акчасыннан башкарыла.

10. Гражданлык өчен мәгариф учреждениеләрендә укучылар, тәрбияләнүчеләр укыту планында каралмаган чараларга ирекле йөрергә хаклы.

11. Төзәтү эшләре хезмәтендәге учреждениеләрдә тотылучылар өчен әлеге учреждениеләрнең администрациясе һәм дәүләтнең мәгарифкә идарә органнары тарафыннан төп гомуми (тулы булмаган урта) белем бирү, башлангыч һөнәр белеме алу өчен, шулай ук үзлегеннән уку өчен шартлар тудырыла.

12. Законнарда каралган дәүләт мәгариф учреждениеләре укучыларына бирелгән ташламаларга хокук дәүләткә карамаган, дәүләт аккредитациясе булган мәгариф учреждениеләре укучыларына да кагыла.

13. Аккредитацияләнмәгән мәгариф учреждениеләрендә, гаиләдә белем алу һәм үзлегеннән белем алу рәвешләрендәге гомуми белем әзерлеге алган гражданнар тиешле төрдәге аккредитацияләнгән мәгариф учреждениеләрендә экстернат рәвешендә аттестация алырга хаклы.

14. Гомуми белем мәктәпләрендә укучылар, тәрбияләнүчеләр укудан буш вакытта хезмәт законнарында каралган тәртиптә эшкә

урнаша алалар.

15. Гражданлык мәгариф учреждениеләрендә укучыларны, тәрбияләнүчеләрне белем бирү программасында каралмаган хезмәткә укучылар, тәрбияләнүчеләр һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгыннан башка эшкә җәлеп итү тыела.

46 статья. Тәрбияләнүчеләрнең һәм укучыларның сәламәтлеген саклау

1. Мәгариф учреждениеләре, сәламәтлек саклау органнары белән килешеп, тәрбияләнүчеләрнең һәм укучыларның исәнлеген һәм сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыра.

2. Укучыларның дәресләр режимы, уку һәм хезмәт йөкләнеше мәгариф идарәсе органнары күрсәтмәләре нигезендә, сәламәтлек саклау органнары белән килешенеп, мәгариф учреждениесе уставында билгеләнә.

3. Укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең уку-житештерү эшчәнлеге, практикалары барышында укыту, хезмәтне саклау өчен имин шартлар тудыру буенча җаваплылык законнар нигезендә мәгарифкә идарә органнарының, мәгариф учреждениеләренең , предприятиеләренең, учреждениеләренең һәм оешмаларының урындагы затларына йөкләнә.

4. Озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен укыту-сәламәтләндерү учреждениеләре, шул исәптән шифаханә тибындагылар да оештырыла. Дәресләр дәвалану учреждениеләрендә дә, өйдә дә үткәрелергә мөмкин.

5. Мәгариф учреждениесенә медицина хезмәте күрсәтүләрне сәламәтлек саклау органнары тәэмин итәләр. Мәгариф учреждениесе медицина хезмәткәрләренә тиешле шартлар тудырылган бина (бүлмә) бирергә тиеш.

6. Мәгариф учреждениесендә туклануны оештыру дәүләт идарәсенең җирле органнарына, җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

Укучыларны, тәрбияләнүчеләрне туклandыруга һәм аларның сәламәтлеген саклауга чыгымнарның инфляция нәтиҗәсендә үсүе дәүләт тарафыннан тулысынча компенсацияләнә.

47 статья. Мәгариф өлкәсендә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) хокуклары һәм бурычлары

1. Балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) балалары төп гомуми (тулы булмаган урта) белем алганчыга кадәр укыту рәвешен һәм мәгариф учреждениесенең төрен сайларга, баласына шәхес буларак ихтирам таләп итәргә, аның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен якларга, балаларының тиешенчә белем алуы өчен кирәкле шартларны тудыруга ирешергә, укытучыларның, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренең һәм гамәлгә куючыларның балаларны укыту һәм тәрбияләү белән бәйле гамәлләренә карата дәүләт хакимияте һәм хөкем органнарына шикаять белдерергә һәм мәгариф учреждениесенә идарә итүдә катнашырга хаклы.

2. Ата-аналар (законлы вәкилләр) балага башлангыч гомуми, төп гомуми (тулы булмаган урта) һәм урта (тулы) гомуми белемне гаиләдә бирергә хаклы. Бу очракта ата-аналар (законлы вәкилләр) белән мәгарифкә идарәнең тиешле органы арасында шартнамә төзелә, анда баланың, гаиләнең, җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен исәпкә алып, тиешле хокукый, икътисадый һәм башка шартлары, якларның йөкләмәләре билгеләнә. Баланы аттестацияләү нәтиҗәләре буенча гына һәм бары тик хөкем тәртибендә шартнамә мәгарифкә идарә органнары инициативасы белән юкка чыгарылырга мөмкин. Гаиләдә белем алучы бала уңай аттестацияләнсә, белем алуын мәгариф учреждениесендә дәвам итәргә хаклы.

3. Укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) мәгариф учреждениесе уставын үтәргә тиеш һәм алар балаларны гаиләдә тәрбияләү өчен җаваплы.

48 статья. Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү

1. Мәгариф учреждениесендә хезмәткәрләр туплап тәртибе аларның уставы нигезендә җайга салына.

Белем цензына ия булган һәм һөнәр сыйфатларының квалификацияле таләпләренә җавап бирә торган зат кына мәгариф учреждениеләрендә педагогик эшчәнлеккә тартыла ала, бу таләпләр тиешле типтагы һәм төрдәге мәгариф учреждениеләре турындагы бердәм нигезләмәләр белән билгеләнә.

2. Хөкем карары яисә медицина мәгълүматлары буенча мәга-

349

риф учреждениесендә педагогик эшчәнлек алып бару тыелган затларның, шулай ук билгеле бер җинаятьләр өчен хөкем ителгән затларның мәгариф учреждениесендә педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүенә юл куелмый. Медицина буенча рөхсәт бирмәүче тиешле мәгълүматларның һәм җинаять составының исемлеге законнар белән билгеләнә.

49 статья. Шәхси хезмәт рәвешендәге педагогик эшчәнлек

1. Керем алуга бәйле шәхси хезмәт рәвешендәге педагогик эшчәнлек эшкуарлык дип карала һәм законнар нигезендә теркәлергә тиеш.

2. Шәхси хезмәт рәвешендәге педагогик эшчәнлек лицензияләнми. Аны теркәгәндә гариза бирүче дәүләт идарәсенең тиешле органына гариза һәм теркәү җыемын түләү турында документ кына тапшыра.

3. Теркәлмәгән шәхси хезмәт педагогик эшчәнлегенә юл куелмый. Шундый эшчәнлек белән законнарны бозып шөгыльләнгән физик затлар законнар нигезендә җаваплы булалар. Андый эшчәнлектән алынган барлык керемнәр билгеләнгән тәртиптә тиешле җирле бюджет керемен алынырга тиеш.

50 статья. Мәгариф системасында хезмәт мөнәсәбәтләре

1. Әгәр законнарда башкасы каралмаган булса, мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре өчен эш бирүче булып әлеге мәгариф учреждениесе тора.

2. Мәгариф учреждениесе хезмәткәренең хезмәт мөнәсәбәтләре хезмәт шартнамәсе (контракты) белән җайга салына. Хезмәт шартнамәсенең (контрактының) шартлары хезмәт турындагы законнарга каршы килә алмый.

3. Администрация инициативасы буенча хезмәт турында законнарда каралган хезмәт шартнамәсен өзү нигезләреннән башка, мәгариф учреждениесенең педагогия хезмәткәрен әлеге мәгариф учреждениесе администрациясе инициативасы буенча хезмәт шартнамәсе (контракты) вакыты узганчыга кадәр эштән азат итү нигезе булып түбәндәгеләр тора:

а) мәгариф учреждениесенең уставын бер ел эчендә кабат

210

тупас бозу;

б) укучы, тәрбияләнүче шәхесенә карата физик һәм (яисә) психик көчләү белән бәйле тәрбия ысулларын, шул санда бер тапкыр гына да, куллану;

в) эш урынында алкоголь, наркотик яисә токсик исерү халәтендә булу.

Әлеге нигез буенча эштән азат итү администрация тарафыннан профсоюз ризалыгыннан башка да гамәлгә ашырыла ала.

<u>51 статья.</u> Мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү

1. Мәгариф учреждениесе хезмәткәренә хезмәт хакы һәм эш урыны буенча окладлары хезмәт шартнамәсендә (контрактында) каралган вазыйфасы йөкләмәләрен һәм эшләрен башкарган өчен түләнә.

2. Мәгариф учреждениеләре педагогия хезмәткәрләренең хезмәт хакы һәм эш урыны буенча окладының минималь ставкалары Татарстан Республикасындагы уртача эш хакыннан югарырак күләмдә билгеләнә.

Мәгариф учреждениеләре педагогия хезмәткәрләренең хезмәт хакы һәм эш урыны буенча окладының уртача ставкасы күләме түбәндәге дәрәҗәдә билгеләнә:

- югары һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләренең укытучы-профессор составыннан булган педагогия хезмәткәрләренә - Татарстан Республикасында сәнәгать хезмәткәрләренең уртача эш хакыннан ике мәртәбә артыграк күләмдә;

- укытучыларга һәм башка педагогия хезмәткәрләренә - Татарстан Республикасында сәнәгать хезмәткәрләренең уртача эш хакыннан кимрәк булмаган күләмдә;

- мәгариф учреждениеләренең башка хезмәткәрләренә - Татарстан Республикасында сәнәгать хезмәткәрләренең шуңа тиң категорияләренә билгеләнгән уртача эш хакыннан кимрәк булмаган күләмдә.

3. Мәгариф учреждениесе хезмәт өчен түләүнең рәвешен һәм системасын, өстәмәләрнең һәм өстәлмәләрнең, премияләрнең һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләмнәрен хезмәт өчен түләүгә үзләрендә булган акчалар чикләрендә мөстәкыйль рәвештә билгели.

Әлеге максатлар өчен хезмәткәрнең укыту күләмнәрен тиешеннән артык күтәрү юлы белән акча юллау тыела.

<u>52 статья.</u> Мәгариф хезмәткәрләренең хокуклары, бурычлары, социаль гарантияләре һәм ташламалары

1. Мәгариф учреждениесе хезмәткәре түбәндәге хокукларга ия:

- һөнәр квалификациясен күтәрү;
- мәгариф учреждениесе белән идарә итүдә катнашу;
- намусын һәм абруен саклау, һөнәр эшчәнлеге өчен гадел һәм уңайлы шартлар булдыру.

2. Мәгариф учреждениесе педагогия хезмәткәре тарафыннан һөнәр тәртибен нормаларын һәм (яисә) әлеге мәгариф учреждениесе уставын бозуларны дисциплинар тикшерү язмача рәвештә бирелгән шикаять буенча гына үткәрелә ала. Шикаятьнең күчермәсе бу педагогия хезмәткәренә тапшырылырга тиеш.

3. Дисциплинар тикшерүнең барышы һәм аның нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар мәгариф учреждениесенең кызыксынган педагогия хезмәткәре ризалыгы белән генә игълан ителергә мөмкин. Монда педагогия эшчәнлеге белән шөгыльләнүне тыючы очраклар яисә укучылар, тәрбияләнүчеләр мәнфәгатьләрен яклау зарурлыгы очраклары керми.

4. Педагогия хезмәткәренә законнар нигезендә түбәндәге хокуклар бирелә:

- укыту һәм тәрбияләү ысулиятләрен, уку-укыту ярдәмлекләрен һәм материалларын, дәреслекләрне, укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең белемнәрен бәяләү ысулларын сайлау һәм куллану иреге;
- педагогик инициатива, үзенең фәнни нигезләнгән яисә экспериментал дәлилләүгә ирешкән педагогик тәҗрибәсен тарату;
- пенсия яшенә җиткәнче озак еллар хезмәт иткән өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә пенсия алу;
- авыл җирләрендә, эшче поселокларда (шәһәр тибындагы поселокларда) ягулыгы һәм уты булган түләүсез торак, законнар нигезендә торак мәйданны беренче чиратта алу;
- шифаханәләрдә ташламалы дәвалану;
- законнар нигезендә түләүле ял алу;
- өзлексез эшләү чорында ун ел саен бер елга кадәр вакыт-

ка түләүсез өстәмә ял алу, бу очракта педагогик эш стажы өзелми, мондый ялны бирүнең тәртибе һәм шартлары шушы мәгариф учреждениесенең гамәлгә куючысы тарафыннан һәм (яисә) уставы нигезендә билгеләнә;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бирүче ташламалар.

5. Мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре өчен кыскартылган – атнага 36 сәгатьтән дә артмаган эш вакыты билгеләнә.

6. Мәгариф учреждениеләренең авыл җирләрендә, шәһәр тибындагы эшче поселокларда яшәүче педагогия хезмәткәрләре авыл хуҗалыгы белгечләре өчен каралган ташламалардан файдаланырга хаклы.

7. Авыл хуҗалыгы буенча югары һөнәр һәм урта һөнәр мәгариф учреждениеләрен тәмамлаган белгечләргә үз хуҗалыкларын булдыру өчен бирелә торган бер мәртәбәлек пособие бирү шартлары һәм тәртибе педагогия югары һәнәр һәм урта һөнәр мәгариф учреждениеләрен тәмамлаучыларга һәм авыл җирендәге мәгариф учреждениеләренә эшкә килгән башка белгечләргә дә кагыла.

8. Мәгариф системасының укыту һәм фәнни лабораторияләре, укыту-житештерү, житештерү остаханәләре (цехлары), һәм укыту хуҗалыклары предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары, хезмәткәрләренә тиешле житештерүләр хезмәткәрләре өчен билгеләнгән ташламалар һәм өстенлекләр дә кагыла.

9. Мәгариф учреждениеләренең педагогия хезмәткәрләренә (шул исәптән эшчәнлеге белем бирү барышына бәйле җитәкче хезмәткәрләргә), аларны китап нәшрияты продукциясе һәм көндәлек матбугат белән тәэмин итүдә булышу максатларында, югары һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләрендә һәм тиешле өстәмә һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләрендә хезмәт өчен түләүнең бер ярым минималь күләмендә, ә башка мәгариф учреждениеләрендә – хезмәт өчен түләүнең бер минималь күләмендә ай саен акчалата компенсация түләнә. Бирелгән акчалата компенсациягә салым салынмый.

10. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, оешмалар һәм предприятиеләр мәгариф хезмәткәрләренә үз вәкаләтләрендә өстәмә социаль ташламалар бирә алалар.

11. Мәгариф учреждениеләренең педагогия хезмәткәрләре өчен даими рәвештә гамәлгә куючы исәбеннән түләүсез медицина

тикшерүе оештырыла.

12. Ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәүче учреждениеләр каршында төзелүче мәгариф учреждениеләренең һәм укыту-консультация пунктларының хөкем ителүчеләр белән эшли торган хезмәткәрләренә пенсия билгеләгәндә хөкем ителгәннәр белән эшләүчеләр өчен ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәүче учреждениеләрнең хезмәткәрләре өчен каралган аерым хезмәт шартларына бәйле тәртип һәм шартлар кулланыла.

53 статья. Мәгариф хезмәткәрләрен бүләкләү

Киләчәк буынны укытуда һәм тәрбияләүдә ирешкән күренекле уңышлары, мәгариф системасын үстерүгә үзләреннән зур өлеш керткәннәре өчен мәгариф хезмәткәрләре түбәндәге бүләкләүләргә тәкъдим ителергә мөмкин:

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә, мактаулы исемнәрен бирүгә;
- премияләргә һәм матди бүләкләүнең башка төрләренә.

VI бүлек. Мәгариф системасында халыкара эшчәнлек

54 статья. Халыкара хезмәттәшлек

1. Мәгариф идарәсенең барлык дәрәҗәләрдәге дәүләт органнары, мәгариф системасы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары чит ил оешмалары һәм халыкара оешмалар белән турыдан-туры элемтә урнаштыра алалар.

2. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар Татарстан Республикасында белем алырга, яңадан әзерлек үтәргә һәм квалификацияләрен арттырырга хокуклы. Укыту шартлары Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрендә билгеләнә.

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрендә Татарстан Республикасының мәгариф турында законнарында каралган кагыйдәләрдән башкасы билгеләнсә, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

3. Татарстан Республикасы гражданнары законнар нигезендә чит илләрдә белем алу хокукына ия.

55 статья. Тышкы икътисадый эшчәнлек

1. Мәгариф идарәсенең дәүләт органнары, мәгариф учреждениеләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мөстәкыйль рәвештә тышкы икътисадый эшчәнлек алып барырга, банкларда һәм башка кредит оешмаларында валюта исәпләре булдырырга хокуклы.

2. Мәгариф учреждениесенең тышкы икътисадый эшчәнлегеннән кергән валюта акчалары аның милке була яисә аның оператив идарәсенә керә һәм тартып алынырга тиеш түгел".

**2 статья.** Әлеге Закон, 51 статьяның тиешле норматив актлар кабул ителгәннән соң гамәлгә кертелүче 2 пунктыннан тыш, матбугатта басылып чыккан көннән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 2 июле
№ 1247